**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19 май 2026 ел № 544

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2026 елның 21 гыйнварындагы 41 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив хокукый актны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 2026 елның 21 гыйнварындагы 41 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күрсәтелгән карар белән расланган гражданнарны милеккә җир кишәрлекләрен түләүсез бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

Знче кушымтаның 2 пунктында «Шәхесне таныклый торган документлар» сүзләрен «Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклый торган башка документ Россия Федерациясе законнары нигезендә яисә хезмәт күрсәтүче органнарда, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә «физик затларны биометрик персональ белешмәләрдән файдаланып идентификацияләү һәм (яисә) аутентификацияләү турында, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 29 декабрендәге 572-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 10 һәм 14 статьяларында каралган мәгълүмати технологияләр кулланып идентификацияләү һәм (яисә) аутентификацияләү юлы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә..

Җитәкче Ә.К. Габдуллин